**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**2024 елның 25 марты** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, ул 2024 елның 25 мартында 14 сәгать 00 минутта түбәндәге мәсьәләләр буенча: «Сез Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 28 октябрендәге 6 номерлы карарына 3 пунктка үзгәреш кертүгә һәм аны яңа редакциядә бәян итергә ризамы (алга таба - карар):

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контроле уздыру, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контроле уздыру)

" РИЗА" "КАРШЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган халык җыенында катнашучылар исемлегенә 297 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 156 кеше катнашкан, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 156 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Урман торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I, II төркем (ялгыз яшәүче) инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәгән затлардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешеп бетәсезме?» дигән сорау буенча:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контроле уздыру, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контроле уздыру) карар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм

төзелеш контроле уздыру, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контроле уздыру)

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф. Х. Хисаметдинова